ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2022 г.Лениногорск № 1172

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 8 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы мобилизацияләнгән гражданнарының гаиләләренә ярдәм итү чараларының исемлеген раслау турында» 1123 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләүне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары, мобилизацияләнгән гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 8 ноябрендәге 1123 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында»;

1.2 1пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында формалашкан «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнарга, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашып һәлак (вафат) булган гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм вафат булган (махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә вафат булган) гражданнар гаиләләренә бирелә торган ярдәм күрсәтү чараларының исемлеген расларга;

1.3 «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 8 ноябрендәге 1123 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының мобилизацияләнгән гражданнары гаиләләренә ярдәм итү чаралары исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итү чаралары исемлеге»;

1.4 Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итү чаралары исемлеге түбәндәге эчтәлектәге 4 һәм 5 пунктлар белән тулыландырырга:

«4. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы мәктәпләрдә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә (1нче, 2нче, 3нче спорт мәктәпләре, хоккей буенча спорт мәктәбе, «Трамплиннан чаңгыда сикерү һәм ике төр ярыш буенча» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе) спорт түгәрәкләрендә һәм өстәмә белем бирү секцияләрендә дәресләр өчен түләүдән азат ителү, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар балаларының һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган гражданнарның гаиләләренең «Дружба» һәм «Олимпия» җәйге сәламәтләндерү лагерьларында бушлай ял итүе.

«5. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына һәм махсус хәрби операциядә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына караган муниципаль мәдәният учреждениеләре музейларында, мәдәният һәм өстәмә белем бирү учреждениеләренең үзешчән сәнгать түгәрәкләренә бушлай

йөрүе.».

2. Әлеге карарның гамәли көче 2022 елның 21 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.leninogorsk.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), вакытлы матбугатта – «Лениногорские вести» газетасы аша халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты житәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72